| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 15 апрель № 229

г. Казань

Азнакай муниципаль районында җир кишәрлеген бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең Азнакай муниципаль районында урнашкан, дәүләт милкендә булган 0,3358 гектар мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлеген 16:02:140203:345 кадастр саннары белән Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәдә күрсәтелгән чикләрдә, җир асты байлыкларыннан файдалану максатларында, сәнәгать җирләре һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\229.docx